БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» 10 2022 ел № 287

«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 августындагы 261 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, 2022 елның 14 апрелендәге 02-08-01-22 номерлы прокуратура протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 19 августындагы 261 номерлы карары белән расланган Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктчаны өстәргә:

«1.1) шәхси торак төзелеше объектларын төзүне, реконструкцияләүне («Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш);»;

1.2. 1 статьяның 1.5 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы төзелешләр һәм корылмалар төзү, аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;»;

1.3. 2.5 статьяның 2.5.1 пунктындагы 6 пунктчасына “, блоклы төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, бер рәттәге блоклы төзелеш йортларының барлык хокук ияләренең ризалыгын" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" интернет -ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары итеп йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов